| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ**<br>29.01.2026 | п.г.т. Алексеевское | **КАРАР**<br>№ 24 |

**2024 елның 05 июлендәге №100 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә хакында» Совет карарына үзгәрешләр кертү турында (2024 елның 14 декабрендәге №112 дәге үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп,

**Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карар кабул итте:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советының 2024 елның 05 июлендәге №100 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 15.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

- ТР Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы: Алексеевск ш.т.п., Павелкин ур.18 йорт;
- Күпфункцияле үзәк, Алексеевск ш.т.п., Совет мәйданы, 2 йорт;
- Район мәдәният йорты, Алексеевск ш.т.п., Совет мәйданы, 1а йорт;
- Үзәк китапханә, Алексеевск ш.т.п., Казаклар ур., 12 йорт.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары В.В. Увакинага йөкләргә.

**Алексеевск шәһәр җирлеге Башлыгы, Совет рәисе** **С.А. Демидов**